КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1049

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үзара салым акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 декабрь, 909 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үзара салым акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 декабрь, 909 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 3 нче; 2015 ел, 12 февраль, 85 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 706 нчы; 2018 ел, 9 ноябрь, 984 нче; 2021 ел, 19 ноябрь, 1106 нчы; 2022 ел, 23 декабрь, 1397 нче; 2023 ел, 29 ноябрь, 1532 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «муниципаль берәмлекләре» сүзләрен «муниципаль районнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «муниципаль берәмлекләре» сүзләрен «муниципаль районнары» сүзләренә алмаштырырга;

1[1] пунктта «муниципаль берәмлекләренең» сүзләрен «җирлекләренең» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елдан башлап бирелә торган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен билгеләү максатларында кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин